**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«10» 11 2025 ел Яр Чаллы ш. № 3691

ТР Тукай муниципаль районы «Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы «Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы «Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 11 декабрендәге 5523 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Л.Н. Маняпов

Муниципаль район Башкарма комитетының 2025 елның «10» 11 3691 номерлы карарына 1 кушымта

2025 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Мәктәпкә әзерлек» | 600,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Кызыклы инглиз теле» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Оста куллар» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

2026 елның 1 гыйнвареннан

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Мәктәпкә әзерлек» | 650,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Кызыклы инглиз теле» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Оста куллар» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы «Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ директоры ____________ З. А. Гыймазиева

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары ____________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы «Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Мәктәпкә әзерлек»** - баланы һәрьяклап үстерүгә юнәлтелгән, бу булачак укучының башлангыч мәктәбендә белем алуга әзерлек формалаштыруны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 51,1 кв.м., балалар саны - 8.

2. **«Кызыклы инглиз теле»** - сөйләм күнекмәләрен үстерүгә, тел мохитенә чумуга һәм чит телне өйрәнүгә кызыксыну уятуга юнәлдерелгән.

Әлеге хезмәт 7 яшьтән алып 10 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 51,1 кв.м., балалар саны - 10.

3. **«Оста куллар»** - баланың комплекслы усешенә, иҗади уз-узен практик белем һәм әхлакый тәрбия белән бергә юнәлтелгән (ярма белән бәйләү).

Әлеге хезмәт 8 яшьтән алып 10 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 51,1 кв.м., балалар саны - 8.

ТР Тукай муниципаль районы
«Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе»
МБГББУ директоры ____________ З. А. Гыймазиева